**Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы № 103 12.01.2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 августындагы 89 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм остәмәләр кертү турында ( 2015 елның 13 ноябрендәге 16 номерлы, 2016 елның 07 декабрендәге 45 номерлы, 2019 елның 23 апрелендәге 132 номерлы, 2020 елның 03 февралендәге 162 номерлы, 2021 елның 15 мартындагы 20 номерлы, 2021 елның 11 октябрендәге 37 номерлы, 2023 елның 01 февралендәге 75 номерлы, 2023 елның 20 сентябрендәге 92 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 августындагы 89 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү ( 2015 елның 13 ноябрендәге 16 номерлы, 2016 елның 07 декабрендәге 45 номерлы, 2019 елның 23 апрелендәге 132 номерлы, 2020 елның 03 февралендәге 162 номерлы, 2021 елның 15 мартындагы 20 номерлы, 2021 елның 11 октябрендәге 37 номерлы, 2023 елның 01 февралендәге 75 номерлы, 2023 елның 20 сентябрендәге 92 номерлы турында карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең 9.2 бүлеген 1.1 пункты белән тулыландырып, түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешне кертергә:
«1.1. Муниципаль хезмәткәр «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25

декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтларын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында әлеге Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән очракта, җаваплылыктан азат ителә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Утырышта рәислек итүче муниципаль
берәмлекнең вәкиллекле органы
Әлкәй авыл җирлеге Азнакай муниципаль
районы депутаты №4 сайлау округыннан С.З.Зиннурова

АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН
АЛЬКЕЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002494
КПП 164301001